# Гиниятова Фәхриямал Әхмәтша кызы.



Гиниятова Фәхриямал Әхмәтша кызы 1927 елның 15 нче сентябрендә Югары Сон авылында дөньяга килә.

Фәхриямал апаның яшьлеге сугыш чорына туры килә. Сугыш башланган көнне бүгенгедәй хәтерли ул. Сугыш... Онытырлыкмы соң бу сүзне? Безнең илебез 70 ел тыныч тормышта яшәсә дә, сугыш китергән кайгы-хәсрәтне онытырлык түгел.

Сугыш башланганда Фәхриямал апага нибары 14 яшь була. Иртәнге сәгать 5 тә радиодан тынлыкны бозып, илебезгә немец гаскәрләре сугыш башлады дигән шомлы хәбәр тарала. Тыныч тормыш кайгы-хәсрәткә алышына.

Сугышның беренче көненнән үк Фәхриямал апаның өч абыйсын да сугышка алып китәләр. Әтисен карт һәм авыру сәбәпле сугышка алмыйлар. Сугышта бер абыйсы үлә, аның кая җирләнгәнен дә белмиләр.

Фәхриямал апа 1940 нчы елда амбарда эшли башлый. 1942 нче елны тракторга укый. Ул 1948 нче елга кадәр кабинасыз тракторларда көнен,төнен бер итеп эшләп, иген иккән.

-Тракторда эшләгәндә аякка кияргә чабата да юк иде. Миңа олы размерлы ирләр ботинкасын бирделәр, -дип сөйли Фәхриямал апа.

1948-1952 нче елларда Чебоксарда сыер сауган.

Сугыштан соңгы елларны да басуларда бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр бил бөкте ул, ләкин беркайчанда тормыш авырлыгыннан зарланмады.

Тормыш иптәше Харис абый белән бергә 51 ел гомер итәләр. Кеше арасында ким-хур булып яшәмиләр алар, 5 бала тәрбияләгәннәр. Харис абый да сугыш ветераны, ләкин бүгенге көндә арабызда юк инде. Балалар белән шаулап торган, карты белән икесенең мәшәкать тулы көннәрен сагынып искә ала Фәхриямал апа . Балалары хәзер барсы да башлы-күзле, үз тормышлары белән авылыбызның үрнәк гаиләләре булып гомер итәләр. Ул үзенең тормышыннан канәгать, хәзерге вакытта улы Равис, килене Вәлия тәрбиясендә оныкларына сөенеп яшәп ята.